ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ӘКИЯТЛӘРЕ

ТЫЛСЫМЛЫ ЧИШМӘ

ТАВИЛ ХАҖИӘХМӘТОВ рәсемнәре



ТЫЛСЫМЛЫ ЧИШМӘ

ТИЛЕМСӘГӘ-ТИЛЕ БӘХЕТ

БАЙ ҺӘМ БАБАЙ

БЕР МӘЧЕ ҺӘМ ИКЕ МАЙМЫЛ



КӘКРЕ КАЕН ТЕРӘТКӘН



ОЯТСЫЗ ӘТӘЧ

ЧӘҮЧӘЛӘК ХАТЫН

ИКЕ КОЯШ

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 1984

КӘКРЕ КАЕН ТЕРӘТКӘН

Татар халык әкияте



Борын заманда бер алдакчы кеше булган, ди. Ул теләсә кемне алдалый ала икән. Үзен бик акыллыга санап йөргән бер бай кеше:

— Мин шул алдарга очрасам, һич тә алдатмас идем,— дип күкрәк суга икән.

Бервакыт бу кеше, юл буйлап барганда, күрә: юл буенда әлеге алдар бер кәкре каенны терәтеп тора, имеш. Бай аның янына барган да:

— Я, дус, сине алдарга бик оста дип әйтәләр, мине дә алдый алырсыңмы икән, алдап кара әле,— дигән.



Алдар әйткән:

— Нигә сине алдый алмам икән? Бик тиз алдар идем дә, янымда алдар капчыгым юк бит, өйдә калды,— дигән.

Бай, аны-моны уйламыйча, алдарга әйткән:

— Бар алайса капчыгыңны алып кил, мин монда көтеп торырмын,— дигән.

Алдар аңа әйткән:

— Өйгә бик кайтыр идем дә, менә бу каен аварга тора, китәргә ярамый бит,— дигән.

Бу кеше, бик үрсәләнеп:

— Барсана, зинһар, капчыгыңны китерсәнә, син килгәнче, каенны үзем терәтеп торырмын,— дип, кәкре каенны терәтеп калган.

Алдар шул китүдән киткән, ди, ә теге бай әле дә булса кәкре каенны терәп тора, ди.

ЧӘҮЧӘЛӘК ХАТЫН

Рус халык әкияте



Бер ир белән хатын гел ызгышып яшәгән, ди. Хатыны бик чәүчәләк, кире булган, ди. Гел кирегә сукалый икән.

Бервакыт, ерак болыннан кайтып килгән чакта, ире кисәтеп әйткән:

— Упкын янынннан узганда сулгарак каер, егылып төшәрсең,— дигән.

Хатын юри уңгарак каерып, упкын янында тырыпдап сөйләнә, ди.



Шулчак аяк астында туфрак убып, хатын упкынга очкан.

Агай бик кайгырган, упкын янында озак басып торган һәм өенә кайтып киткән.

Бер-ике көн узгач, төн уртасында кемдер ишек шакый икән. Ишекне ачып җибәрүгә, агай калтырап төшкән: каршысында койрыгын болгап, ике мөгезле, аяклары тояклы чып-чын җен басып тора, ди.

— Упкынга синең хатының төштеме?

— Минеке. Ник кирәк ул сиңа?

— Ул туп-туры тәмугка элэкте бит! Безгә тәмугта көн бетте, тәмам теңкәбезгә тиде, ташлап



качасылар килә! Кире ал аны, зинһар! — ди җен.

Хатынының исән хәбәрен ишеткәч, агай бик куанган, ләкин үзе сер бирми, ди.

— Кара әле, үз хатының бит, ал инде кире,— дип ялына икән җен.— Аның өчен без сиңа бер капчык алтын бирәбез.

Шулчак агай хатынының баскычтан менеп килүен күргән. Ә җен җайлап кына артка чигенгән дә баскыч астына төшеп качкан.

Икенче көнне болдырдан бер капчык алтын табып алганнар — алдарга йөрәге җитмәгән җеннең.

ТЫЧКАН БЕЛӘН ЕЛАН

Кыргыз халык әкияте



Көннәрдән бер көнне тычкан, азык эзләп, басуга чапкан. Әйләнеп кайтса, ни күрсен, аның оясында елан ята. Чакырылмаган кунактан куркып, тычкан күршеләренә йөгереп кергән.

Ул аларга үзенең кайгысын сөйләп, киңәш сораган: ничек итеп теге еланны куып чыгарырга?

Акыл иясе — тычканнар киңәшкә җыелганнар да үз фикерләрен әйткәннәр.



— Бу өнне ташлап китүдән дә яхшысы булмас! Үзеңә икенче өн казы да шунда яши бир. Синең ояңа кереп елан гаделсезлек эшләгән, ләкин нишләмәк кирәк. Еланга бәйләнсәң, ул сине тотар да ашар.

Бичара тычкан кайгырган-кайгырган да китеп барган. Ләкин ул мондый хөкем белән һич тә килешә алмаган. Кыерсытучыны ничек җәзага тартырга соң? Ул шул турыда уйлана башлаган.

Җәйге кызу көннәрнең берсендә тычкан еланның өн янында кояшта кызынып ятканын күрә. Ә шуннан ерак та түгел, бакчада, агач күләгәсендә бакчачы йоклап ята икән.

Тычкан бакчачы янына йөгереп барган да аның бармагын тешләгән. Бакчачы тычканны куып киткән. Ә тычкан аны елан яткан урынга алып килгән. Шулчак бакчачы еланны күргән дә:

— Бу елан тычканга караганда күп тапкыр зарарлырак! — дип тегене бәреп үтергән.

Тычканга шул гына кирәк тә: ул элеккечә үзенең өнендә яши башлаган.

ИШӘК ҺӘМ ҮГЕЗЛӘР

Каракалпак халык әкияте



Фәкыйрь генә игенченең бер ишәге һәм ике үгезе булган. Үгезләр белән ул җир сөргән, печән, икмәк ташыган. Ишәге исә урамда үлән чемченеп йөргән. Эшсезлектән аптыраган ишәк үгезләрне мыскыл итәргә уйлаган.

— Менә сез печән ашамасагыз, авырыр идегез. Чирле үгез белән кем җир сөрә инде?! Рәхәтләнеп бер ял итәр идегез,— дигән ул.

Үгезләр шулай эшләгәннәр дә! Ашамагач, ябы-



га башлаганнар, ахырда кузгалырлык хәлләре дә калмаган.

Хуҗа кайгыга калган. Кояш чыкмас борын ул, ике үгез көч-хәл белән сөйри торган сукага ишәген җигеп, җир сөрергә тотынган.

— Ник бу хәтле төс-кыяфәтең китте, авырмыйсындыр бит? — дип сораганнар үгезләр кичен ишәктән.

— Авыруын авырмыйм да... Кайтышлый хуҗа белән сөйләштек әле. «Бу үгезләрне итчегә сатып



җибәрәм, чирле үгезләр белән нишлим мин?» ди...

Бу сүзләрне ишеткәч, үгезләр куркуга төшкәннәр. Алларындагы печәнне умырып ашарга керешкәннәр. Иртәнгә хәтле сабанга җигәрлек хәлгә килгәннәр алар.

Игенченең сөенече эченә сыймаган. Үгезләрен ияртеп дә ул басуга киткән. Ишәк аларны озатканда болай ди икән:

— Чынлап та ишәк икәнмен мин. Кара инде, үздән генә юләргә калмадым бит!

ОЯТСЫЗ ӘТӘЧ

Нугай халык әкияте



Чүплектә тибенгәндә, әтәчнең аягына кылчык кадалган, ди. Ул учакта көлчә пешерүче хатын янына килеп:

— Кикрикүк! Аягыма кылчык кадалды! — дип кычкырып җибәргән.

Хатын аның аягыннан кылчыкны алган.

— Син аны утка ат,— дигән әтәч.

Хатын шулай эшләгән дә. Бераздан әтәч кылчыкны таптыра башлаган.

— Кылчыкны кире бирмәсәң, мин синең көлчәңне алам! — дигән.

Әтәч көлчәне эләктереп бер көн, бер төн буе чапкан. Ниһаять, тау итәгендә катык ашап утыручы көтүчегә юлыккан.



— Мә, сиңа кетердәп торган көлчә, аша,— дигән аңа әтәч.

Көтүче көлчәне ашап куйган.

— Кикрикүк! Кире бир көлчәне! Алайса, мин синең сарыгыңны алам!

Әтәч иң симез сарыкны эләктереп чабып киткән. Чаба торгач хан сараена килеп чыккан. Сарайда хан кызының туе, ди. Әтәч сарыкны ханга бүләк иткән. Әтәчне зурлап иң түргә утыртканнар. Кызны күреп, әтәч өнсез калган.

Сарыкны ашап бетергәннәр. Шулчак әтәч ханга әйтә икән:

— Сарыкны кире бир!

— Кунаклар алдында хур итмә мине, әтәч,— дигән аңа хан.

Әтәч үзенекен тукый:

— Я сарыкны, я кызыңны бирәсең!

Моңа ханның бик ачуы килгән. Муенын борып, әтәчне казанга салган. Оятсыз әтәч җәзасын алган. Ә итен кунаклар ашаганнар.

ГАДЕЛ КУЯН

Тува халык әкияте



Бик борын заманда Меге-Сарыч атлы карт яшәгән. Аның бала-чагасы, мал-туары да булмаган. Шуңа күрә авылдан авылга йөреп тамак туйдырырга туры килгән аңа.

Бервакыт ул ике юл чатында зур күн капчык тапкан. Карт моңа бик тә куанган һәм тизрәк капчыкның авызын чишеп җибәргән. Аннан, тешләрен ыржайтып, ач бүре килеп чыккан.

— Әһә, эләктеңме?! Мин хәзер сине кабып йотам,— дигән бүре.

— Соң мин сине коткардым лабаса. Ә син мине ашамакчы буласың. Бу — гадел эш түгел. Безне хөкем итсеннәр,— дигән карт.

Менә карт белән бүре урманга кергәннәр. Бүре тәмам ачыккан, картны хәзер кабып йотарга тора, ди. Ерак та түгел, куян күренеп киткән.

— Ә-һәй, куян! Тукта әле. Качма! Бәхәсебезне чиш! — дип кычкырган карт.

— Бәхәсегез ни турында? — дип сораган куян.

Карт аңа барысын да сөйләп биргән.

— Эшне ныклап тикшерү өчен, бүрене ничек

коткаруыңны үз күзләрем белән күрергә кирәк миңа,— дигән кылый.

Болар өчәүләп юл чатына килгәннәр.

— Капчык кай төштә ята иде, күрсәт әле, картлач,— дигән куян. Карт күрсәткән.

— Хәзер урынына куй,— дигән куян. Карт куйган.

— Ә син, бүре, капчыкта ничек ятканыңны күрсәт,— дигән куян. Бүре капчык эченә кереп яткан.

— Капчык авызы бәйләнгән идеме?

Карт капчык авызын бәйләп куйган.

— Менә эш тә бетте,— дигән куян.— Мин сезне гадел хөкем иттем. Син, картлач, үз юлыңда бул, ә бүре капчыкта ятсын! Хушыгыз!

ИКЕ КОЯШ

Удэгей халык әкияте



Қайчандыр хатыны белән Елдыга атлы бик оста аучы яшәгән. Ул чакны күктә ике кояш булган. Ике кояш кыздырудан агачлар корыган, үләннәр көйгән, елгалар кипкән, җәнлек-җанвар, кош-корт качып киткән, тайгада яшәр көн беткән. Елдыганың балалары да үлгән. Моңа бик ачуы чыккан аучы

ук-җәя ясарга тотынган. Бу ике кояш биек күтәрелми, калкулык башында гына тора икән. Бер көнне алар калкулык өстенә күтәрелүгә, Елдыга җәясен киергән дә болай дип әйткән:

— Җилдәй угым, кояшка туп-туры очып бар. Авыр чакта син бит минем булышчым...

Ук сызгырып очып киткән. Шулчак җирләр селкенеп куйган. Елдыга угы тигән кояш Айга әверелгән,

ә икенче кояш өскә менеп киткән. Менә шул вакытны күк йөзендә бер Ай белән бер Қояш пәйда булган. Агачлар да күккә ашып үсә башлаган, җәнлекләр дә әйләнеп кайткан, кошлар да бөтен тайганы яңгыратып сайрарга тотынган.

БАЙ ҺӘМ БАБАЙ

Куба халык әкияте



Кубада американнар хакимлек иткән чорда була бу хәл.

Амбросио исемле ярлы карт көннәрдән бер көнне америкaн бай яши торган йортка килә.

— Әфәндем,— дип итагатьле генә сүз башлый Амбросио,— менә моның хәтле алтын күпме тора? — ди һәм кулын җәеп алтынның ни зурлыкта икәнен күрсәтә.

Кызыл йөзле бай, бу карт тауда алтын тапкан икән, дип уйлый да пышылдап кына сорый:

— Шундый зурмы?

— Әйе, әфәндем,— дип күзен дә йоммый җавап бирә бабай һәм кулларын тагын да ныграк җәеп җибәрә.

— И-и-и, аны иркенләп хисапларга кирәк! — дип башын чайкый хәйләкәр хуҗа, хезмәтчеләренә ашарга китерергә куша.

Бабай тамагын туйдыра, иреннәрен сыпырып куйгач, америкaн тагын сүз башлый.

— Тиз генә хисаплый торган әйбер түгел бу, кичкә хәтле миндә кунак бул,— ди ул.

Бер атна вакытның узуын сизми дә кала Амбросио: һәр көнне иртән мәрмәр ваннада су коена, җаны теләгән ризыкны ашый, кичләрен кызыл йөзле америкaн белән сәйранга чыга.

Амбросионы ничек кенә сыйларга, ничек кенә аның күңелен күрергә белми инде америкaн! Ниһаять, бер көнне әкрен генә сүз башлый.



— Ул хәзинәңне кайда күмдең соң? Күпме торганын исәпләр өчен, алтынның үзен күрергә кирәк бит,— ди бай.

— Нинди алтын ул? — дип сорый бабай, гаҗәпләнеп.

— Үзең әйттең бит, кулыңны җәеп күрсәттең.

— И әфәндем! — ди Амбросио.— Таптым, дип әйтмәдем бит мин, шундый зурлыктагы алтынның күпме торганын гына сорадым.

ТИЛЕМСӘГӘ — ТИЛЕ БӘХЕТ

Вьетнам халык әкияте



Бик борынгы заманда бер крестьян гаиләсендә ике малай туган. Уллары үсеп җитүгә, әти-әниләре аларга һөнәр сайлаганнар. Олы малайлары кырда эшләргә ярата икән, шуңа күрә аны игенче итәргә, төп йортта калдырырга булганнар. Кече уллары сәүдәгәр һөнәрен ошаткан. Әти-әнисе аңа эш башларга биш ат биргән һәм кисәткәннәр:

— Сәүдәң табышлы булсын. Биргәнгә караганда күбрәк ал, төшендеңме?

Кече малай, ата-ана сүзен тыңлап, атларны базарга алып киткән. Юлда аңа бер карт очраган. Ул алты кәҗә куалап килә, ди. Егет, әти-әнисенең «биргәнгә караганда күбрәк ал» дигән сүзен хәтерләп, картка мөрәҗәгать иткән:

— Әфәндем! Әйдә алышабыз. Син миңа алты кәҗәңне бир, мин сиңа биш ат бирәм,— дигән.





— Җүләрләндеңме әллә?! Кем атны кәҗәгә алыштыра инде?!

Бераз баргач көянтә-чиләккә салып җиде тавык күтәргән карчык очраган. «Юлым бигрәк уңды инде, алты кәҗәне җиде тавыкка алыштырырга кирәк!»— дип карар кылган егет.

Карчык ничек кенә киреләнмәсен, егет сүзен сүз иткән, алты кәҗәне җиде тавыкка алмашкан.

Бара торгач, аңа сигез кабак күтәреп килүче кеше очраган. «Сигез кабак җиде тавыктан күбрәк ич! Алышырга кирәк!»

Сәүдәгәребез сигез кабак күтәреп өйгә кайтып кергән.

— Ай, алла! — дип өнсез калган әти-әнисе.— Биш атны сигез кабакка алыштыралармыни?! Абыеңның басуында кабак беткәнмени?!

Һәм алар аңа сәүдә итәргә рөхсәт бирмәгәннәр. Егет, ачуыннан ярсып, пычак алган да кабакларны ярырга тотынган. Шулчак бер кабак эченнән чылтырап алтын тәңкәләр коелган. «Тилемсәгә — тиле бәхет»,— дип юкка гына әйтмиләр шул.

ТЫЛСЫМЛЫ ЧИШМӘ

Корея халык әкияте



Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер карчык белән бер карт. Тормышлары әйбәт, тик балалары гына юк икән боларның.

Шулай бер көнне карт утынга киткән. Урманга килеп керсә, күрә: кыя астыннан күз яшедәй чиста сулы чишмә агып ята, ди. Чишмә янына килгән дә бу тезләнеп су эчә башлаган. Бер йотым эчкән икән — бөкре җилкәсе турайган. Икенче йотымны эчкән икән — битендәге җыерчыклары беткән.

Карчыгы аны көткән-көткән дә, хәле беткәндер, кая, булышыйм әле үзенә, дип, каршы чыккан. Бара икән карчык, бара икән, күрә: юл буйлап бер яшь егет килә, ди.

— Минем картымны очратмадыңмы? — дип сорый карчык.

Егет шаркылдап көлеп җибәргән:

— Яхшылабрак кара, карчык! Әллә үзеңнең Кимыңны танымыйсыңмы?

Шулай дигән дә егет аны тылсымлы чишмә янына алып барган. Карчык та, ике йотым су эчүгә, япь-яшь кызга әверелгән.

Егет белән кыз, кулга-кул тотынышып, өйләренә кайтсалар, күршеләре боларны танымый икән. Шуннан Ким аңа барысын да сөйләргә керешкән.

— Әйт тизрәк, кайда ул чишмә? — дигән күршеләре һәм, Ким сөйләп бетергәнне дә көтмичә, чыгып та чапкан.

Кич җиткәч, Ким күршеләренә керсә, ул һаман өйдә юк икән. Ким тизрәк чишмә янына йөгергән. Килеп җитсә, күршесе юк, җирдә халат белән эшләпәсе генә калган, ди. Эшләпәне күтәреп караса, ни гаҗәп, эшләпә астында бер сабый тыпырчынып ята, ди.

— Әй, җүләр, җүләр! Тылсымлы суны шулай күп эчәргә ярыймыни? — дигән Ким.

Аннары сабыйны халатка төргән дә өйләренә алып кайткан. Хатыны, бала күргәч, бик сөенгән.

Шулай итеп, алар өчәүләшеп бик бәхетле тормыш белән яши башлаганнар.

БЕР МӘЧЕ ҺӘМ ИКЕ МАЙМЫЛ

Индонезия халык әкияте

Шулай бервакыт юл буйлап җырлый-мырлый мәче килә икән. Агач ботагындагы шөпшә оясына карап торган ике маймылны күргәч, туктап калган бу.

— Әй, мәче, белмисеңме, нәрсә бу? — дип сораганнар тегеләр.

— Ә-ә... минем бабайның барабаны ул.

— Бер генә сугып карыйк әле, ә?!

— Юк, юк, ярамый, бабай ачулана.

— Ул монда юк бит,— дип ялынган маймыллар.

— Ярый инде алайса, сугып карагыз,— дигән мәче.— Тик мин качам, бабай күрсә, эләктерәчәк.



Мәче күздән югалгач, маймыллар таяк алалар да шөпшә оясына китереп сугалар. Шөпшәләр маймылларның башын, колагын, аркасын, муенын чага башлый. Теге мескеннәр алга-артка карамыйча чабарга керешәләр... Каршыда буа күргәч, килгән уңайга суга чумалар. Шөпшә күченең гүләве тынгач кына баш калкыталар. Карасалар, яр буенда әлеге мәче утыра. Тәбәнәк кенә бер куакка сөялгән дә авызын ерган. Ә куакта кып-кызыл борычлар эленеп тора икән.

Маймыллар мәче янына киләләр дә сорыйлар моннан:



— Карале, мәче, нишлисең син монда?

— Бабай бакчасын саклыйм. Җимешләр өлгергән.

— Нинди җимеш ул? Безгә авыз итәргә ярыймы аны?

— Ярый. Тик бабай ачулана... Мин качып торыйм,— ди аларга мәче.

Маймыллар мәче күздән югалганны гына көтеп торалар да ашыга-ашыга авызларына кызыл борыч тутыра башлыйлар. Һәм кинәт... аларның авызына ут капкандай була, күзләреннән яшь ага, иреннәре бүлтәеп чыга.

Шул көннән бирле маймыллар үрле-кырлы сикерүләреннән һаман туктый алмыйлар, ди.

АЙ ЮРГАНЫ

Төньяк Америка индеецлары әкияте



Шулай бер хатын басуда эшли, янында балалары уйнап йөри икән.

Кинәт кенә салкын җил исеп куйган. Аннары яңгыр яварга тотынган, бар җирне су баса башлаган.

Ана балаларын күтәргән дә пальма яфракларыннан үреп ясалган куышка йөгергән. Ләкин су аның юлын бүлгән. Ул, бәләкәй баласын алып, карт имән башына менеп киткән, ә зуррагы алар артыннан үзе үрмәләгән.

Шулчак кара болыт арасыннан якты ай ялтырап киткән.

— Якты ай! Балаларым суыктан калтырый, мин

аларны җылыта алмыйм. Кызган аларны, кызган сабыйларымны! Ярдәм ит безгә! — дип ялварган ана.

Ай аның сүзләрен тыңлап торган да кара болытлар арасына кереп югалган. Балалар да, әниләре дә йокыга талган. Ә түгәрәк ай эшкә керешкән. Ул төне буе болыт ертыкларыннан йон эрләгән.

Таң атуга, ана белән балалар уянсалар, дөнья шундый да җылы икән! Ә агачлар... барысы кабарып торган соргылт-яшел юрганга төренгәннәр, ди.

— Әнкәй! — дип кычкырган балаларның олы-



сы.— Бөтен җир юрган ябынган. Менә нигә җылы икән! Ай синең сүзеңне ишеткән! Болытларны сүтеп, юрган тукыган да агачка элеп куйган!

— Әйе, балалар! Ай сүзебезгә колак салган. Күк аязган, ә болытлар җылы юрганга әйләнгән.

Алар агач башыннан төшкәннәр дә өйләренә кайтып киткәннәр.

Шул көннән башлап агачларның кәүсәсендә соргылт-яшел мүк барлыкка килгән. Индеецлар аңа ай юрганы дип исем биргәннәр.

ДАВЫЛ ҺӘМ МИЧКӘ

Япон халык әкияте



Шәһәр читендәге бер йортта мичкә ясаучы кеше яшәгән. Эше һич тә алга бармаган аның, шуңа күрә тормышы да бик авыр булган.

Шулай бер көнне мичкә ясаучы тәрәзәдән караган да хатынына әйтә икән:

— Карале, давыл чыккан бит! Болай булгач, байыйбыз инде!

— Давылдан кем баеган, юләр! — дип орышкан аны хатыны.

— Әй, бу хатыннарны! Ирләрнең сүзен тыңламыйча, килгән бәхетне качыралар.

— Давыл нинди бәхет китерсен, ди?

— Беләсеңме, хатын?.. Көчле җил искәндә, тузан күтәрелә. Тузан кешеләрнең күзенә керә. Менә безнең бәхет шул инде.

— Кеше күзенә тузан керүдән нинди бәхет булсын?!

— И-и, юләр! Тузаннан аларның күзләре авырта башлый, җирдә бик күп кеше сукырая. Ә сукыр кеше нигә ярый? Сукырларның уйнап-җырлап, хәер сорашып йөрүдән башка чарасы калмый. Ә нәрсәдә уйный инде алар? Билгеле, сямисәндә. Менә безнең бәхет шул инде.

— Сямисәндә уйнаудан безгә нинди бәхет килсен, ди?

— И-и, юләр! Сямисәнне мәче тиресеннән тарттыралар бит. Сямисән кирәк икән — димәк, мәчеләр

дә кирәк. Шулай итеп, бөтен мәчеләрне кырып бетерәләр. Менә безнең бәхет шул инде.

— Мәчеләрне кырып бетерүдән безгә нинди бәхет килсен, ди?

— Мәчеләр булмагач, амбар-келәтләрдә тычкан үрчи. Тычканнар бөтен мичкәләрне тишкәләп бетерә. Димәк, кешеләргә яңа мичкәләр кирәк була. Бөтен халык безгә агыла. Минем эш гөрләп бара башлый. Шулай итеп, без дөньядагы иң бай кешегә әйләнәбез! И-их!

АЖДАҺА

Инглиз халык әкияте





Яшәгән, ди, дөньяда Комодо атлы бер аждаһа. Ул авызыннан ут бөркегән чакта, тирә-юньдәге халык дер калтырап тора, аның килүен ишеткәч, бар да качып бетәләр икән.

Көннәрдән бер көнне аждаһа Сьюзи исемле кызны очраткан. Комодоны күргәч, бу кызның исе дә китмәгән, ди.

— Нигә авызыңнан ут бөркисең син? — дип сораган кыз.— Бөтен кешене куркытасың бит!

— Һем,— ди икән аждаһа,— мин... һем... мин...







белмим. Бу турыда уйлаганым юк иде. Нигә, әллә куркытырга ярамыймы?

— Билгеле, ярамый,— дигән Сьюзи.

— Алайса бүтән куркытмам,— дип вәгъдә биргән Комодо.

Алар саубуллашканнар, Сьюзи өйләренә кайтып киткән. Инде караңгы төшкән булса да, фонарьчы Чарли нишләптер утларны кабызмый икән. Кешеләр караңгыда юл таба алмый аптырап беткәннәр.



Ә Чарли бу вакытта өендә йоклап ята икән. Ул кичә кичен бик арыган булган. Шәһәр башлыгы сэр Уильямның моңа бик тә ачуы чыккан.

Шуннан Сьюзи Комодо яши торган мәгарәгә йөгереп барган да аждаһаны шәһәргә алып килгән. Алар икәүләшеп бөтен урамнарны йөреп чыкканнар: аждаһа, авызыннан ут бөркеп, фонарьларның һәммәсен дә кабызган.

Шәһәр кешеләре бик сөенгәннәр. Шуннан бирле алар аждаһадан курыкмый башлаганнар. Һәр елны, Чарли ялга киткән чакта, Комодоны шәһәр фонарьларын кабызырга чакыра торган булганнар.

15 тиен

Әкиятләрне тәрҗемә итүче,
эшкәртүче һәм җыентыкны
төзүче — РАЗИЛ ВӘЛИЕВ

Художник
ХАЗИАХМЕТОВ
ТАВИЛЬ ГИНИАТОВИЧ

ВОЛШЕБНЫЙ
РОДНИК

Сказки

(На татарском языке)



Рецензенты И. Надиров. Редакторы С. Сибгатуллина. Художество редакторы Р. Шәмсетдинов. Техник редакторы Ә. Трофимова. Корректоры Р. Әхмәтьярова.

ИБ 3596

Производствога бирелде 23.12.83. Басарга кул куелды 7.09.84. Формат $60\times90^1/_8$. 100 гр. офсет кәгазе. Печать офсетная. Гарнитура литературная. Учетн. изд. табагы 2,1. Басма табагы 2,0. Усл. кр. отт. 8,0. Заказ З-691. Тиражы 30 000. Бәясе 15 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420084, Казань, ул. Баумана, 19.
Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

ББК 84.3 Тат
Т 40

Т $\frac{4803010200-259}{М132(03)-84}$ 198—84

© Татарстан китап нәшрияты, 1984